СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Үрнәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**22.09.2017 ел** **№9**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Үрнәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | Вак таш сатып алу, юл-урам челтәрендәге вак таш һәм юл өслеген урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү.<br>- Үрнәк авылы Елга арты ур., 1-3 йорт, наратлы авылы 1а-5а йорт, Тау асты ур., 5-10 йорт, Күпер ур. 11 йорт, Урман ур., 11 йорт; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - Түбән Пошалым авылы Комсомол ур., 1-23 йорт;<br>- Югары Пошалым авылы Ленин ур., 10-19 йорт, Мичурин ур., 1-6, 14-18 йорт;<br>- Урта Пошалым авылы Сәдәшев ур., 1-10 йорт, Вахитов ур., 1-10 йорт;<br>- Көтек авылы Комсомол ур., 1-30 йорт;<br>-Казанбаш авылы Җиңү ур., 27-33 йорт, Азина ур., 193-217 йорт, Киров ур., 1-26 йорт;<br>- Дүртөйле авылы Күпер ур., 1-14 йорт;<br>- Апайкина Гарь авылы Үзәк ур., 1-28 йорт;<br>- Казанка авылы Җиңү ур., 2-10 йорт;<br>- Күлтәс авылы Р. Мөбәрәкшин ур., 1-34 йорт, Г. Кәбиров ур., 1-14 йорт;<br>- Гарталовка авылы Урман ур., 10-19 йорт. |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | - Иске Төрнәле, Алга Көек, Тылангыр авылларында урам утларын ремонтлау;<br>- Алга Көек, Апайкина Гарь, Кече Төрнәле авыллары янында җир кишәрлекләрен рөхсәтсез чүплекләр урнаштыру урыннарында рекультивацияләү. |
| 3 | Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм күмү урыннарын булдыру | Алга көек, Күлтәс авылларында зират коймасына материаллар сатып алу һәм ремонтлау;<br>- Күлтәс авылында зират эчендәге агачларны кисү; |
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Кече Төрнәле, Казанбаш, Үрнәк авыллары чишмәләренә материаллар алу һәм ремонтлау;<br>- Үрнәк, Казанка авылларына су башнялары алу. |

Әйе Юк “.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк авылы, Урман ур., 44А йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 йорт.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы И.Р.Камалетдинов

СОВЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ